| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«16» 07 2024 ел

№ 105

Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгының,
Кече Лызи авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе
турында»гы 2018 елның 17 декабрендәге 195нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында
(2023 елның 27 феврале 71нче номерлы үзгәрешләре белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 нчы апреленең 290 нчы номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2024 елның 4 нче июне 252 нче номерлы карары (2022 елның 13 октябрендәге 144 номерлы үзгәрешләре белән)» һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 17 декабрендәге 195 нче номерлы Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районының Keче Лызи авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында «12688» санын «13323» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы, Кече Лызи авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 1 пунктында «17390» санын «18260» санына алмаштырырга;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы, Кече Лызи авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 2 пунктында «9,26» санын «12,86» санына алмаштырырга;

1.4. Карарның 3 нче кушымтасының 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге Советы рәисе А.С.Исмагилов